*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

Дүртенче сан

Декабрь, 2014 нче ел

Бу санда:



1 *Могҗиза булуына ышанасызмы?*



2 *Сездә ничек, бездә шулай - дәресләр кызык үтә*

3 *Ура, каникул! Исәнме, ВК!*



4 *Көн яңалыклары*

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!



Яңа елдан һәр кеше могҗиза көтә. Ничек көтмисең? Капка төпләрендә Кыш Бабай, Кар кызы барлыкка килде. Гимназия ишек алдында нинди генә җәнлекләр юк! Әкият геройларыннан тулы бер галерея! Кардан ясалган сыннар искиткеч матур чыкты. Димәк, тиздән, бик тиздән ЯҢА ЕЛ җитә! Санаулы көннәр, санаулы сәгатьләр калып бара. Укучылар, укытучылар белән шул темага сөйләшәбез.

**Сорауларыбызга гимназия директоры Мирзаянов Азат Фәрит улы җавап бирде:**

**2014 нче ел кайсы ягы белән истә калды?**

Минем өчен бу ел бик тә истәлекле ел булды – үземнең хезмәт юлын башлаган гимназиямә кабат кайттым. Киләчәктә гимназияне республикабызның иң яхшы инновацион белем бирә торган уку йортлары рәтендә күрергә телим. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр дә бар. Бердәм булып эшләргә, куйган максатларга ирешү өчен тырышырга кирәк.

**Яңа 2015 нче елга гимназия нинди уңышлар белән килә?**

Укучыларыбызның укуда да, спортта да, сәнгать өлкәсендә дә уңышлары шактый. Республика олимпиадаларының муниципаль этабында катнашып, 66 укучы төрле фәннәр буенча җиңүче һәм призер булдылар. Фән бәйгеләре – укучыларның белемен объектив бәя бирә торган күрсәткеч. Укучыларыбыз республика олимпиадарына ныклы әзерлек белән барырлар, үз белемнәрен аклый алырлар дип ышанам.

Коллективның һәрбер членына, коллегаларыма, барлык укучыларга Яңа ел бары тик яңа уңышлар, шатлык-куанычлар китерсен иде.

**Яңа ел төнендә нинди могҗиза булуын телисез?**

Кешеләрнең могҗизага ышануын телим. Могҗизага ышану – үзе могҗиза!

**Ә сез Кыш бабайга ышанасызмы?**

***Сорауга 8а сыныфы укучылары җавап бирде.***

**Руслан:** Мин кечкенә вакытта Кыш Бабайның чын булуына ышана идем. Казанда яшәгәндә, (миңа ул вакытта 3-4 яшь) безнең өйгә Кыш Бабай килде, безнең белән чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйнады, ләкин бик тиз китеп барды. Хәзер инде аңласам да, ул вакытта безнең өйгә “чын” Кыш бабай кергәндер кебек тоела.

**Салих:** Беренче тапкыр балалар бакчасында Кыш Бабай күргәч, бик курыкканым истә калган. Чыршы янында елап төшкән фотографиям дә саклана.

**Динә:** Кыш Бабайның тәрбияче апабыз икәнен алкасыннан танып алган идем мин. “Безнең Динәне алдап булмый”, - дип, әни хәзер дә бу моментны искә ала.

**Ринат:** Бәйрәмгә Кыш Бабай белән Кар кызы килүен бөтен кеше көтә, шулай булса гына бәйрәм күңелле. Яңа елның төп атрибутлары ич алар!

**Рафаэль:** Кыш Бабайның үзенә ышанмасак та, күңел белән аның капчыгындагы күчтәнәчләрдән өлеш чыгуын көтәбез. Кыш Бабай табышмаклар әйтә башлагач, зур булсак та, ярыша-ярыша җавапларын эзли башладык. Конфетлары мул иде, тәмле булды! *(көлә)*

**Ленар:** Бишенче сыйныфта Яңа ел алдыннан мин отличник булдым. Гимназиядә кышкы ял лагере башланды. Бер көнне иртән килгәндә, мине сыйныф җитәкчебез Эльмира Василовна каршы алды. “Ленар, сине монда Кыш Бабай белән Кар кызы эзләп кергәннәр иде. Үзеңә очрамадылармы? Отличник Латыпов Ленар монда укыймы, тапшырыгыз, зинһар, кичә өйләрендә туры китерә алмадык диделәр,” – диде һәм кулыма зур шоколад тоттырды. Мин бик аптырадым, өйдә генә утырмавыма үкендем. Ул көнне без малайлар белән төнгә кадәр урамда уйнадык. Урам буйлап биек “Джип”та Кыш Бабай белән Кар кызы һәм Куян күчтәнәч таратып йөргәнен күргән идем шул... Их, өйдә генә утырсам... Бер нәрсәгә бүген дә аптырыйм: минем отличник булуымны алар каян белгәннәр?..

# СЕЗДӘ НИЧЕК, БЕЗДӘ ШУЛАЙ - ДӘРЕСЛӘР КЫЗЫК ҮТӘ



Дәрестә кагыйдә сөйләп, күнегүләр эшләтү искелек калдыгы инде хәзер. СИНГАПУР МЕТОДИКАСЫН дәресләргә кертә башлагач, уку процессында нинди үзгәрешләр булды? Укучыларга “модный” дәресләр ошыймы? **АСЫЛДА НӘРСӘ СОҢ УЛ – СИНГАПУР ЫСУЛЫ ҺӘМ АНЫ «НӘРСӘ БЕЛӘН АШЫЙЛАР»?** Укучыларыбызга шул сораулар белән мөрәҗәгать иттек.

**Алинә Сәхипгәрәева – гимназия Президенты:** Математика, рус телен без башка мәктәпләрдәге кебек үк өйрәнәбез, ә менә биология, химия, физика, инглиз теле, информатика сингапур ысулы белән укытыла. Миңа калса, һәр ике төр дәреснең дә көчле һәм кимчелекле яклары бар. Дәрестә без бер-беребезгә киңәшче дә, белем тикшерүче дә, укытучы да – бу классны бик берләштерә. Миңа Зөлфирә Мухаровна, Венера Гайсовна, Ләйсән Фагимовнаның дәресләре бик ошый. Структураларны урынлы кулланып, алар бездән дә чын белгечләр ясыйлар. Икенче яктан караганда, бездә аралашу культурасы үсә. Минемчә, бүгенге заманда кеше белән аралаша белү бик мөһим.

**Сафиуллин Ренат - гимназия Укучылар үзидарәсенең Сәламәтлек һәм спорт министры:** Бер өстәлгә дүрт кеше туры килә. Алар партнёрлар, һәр укучының җилкә партнёры (янында утырган классташың) һәм йөз партнёры (каршында утырган классташың) бар, биремнәрне йә бер партнёрың, йә икенчесе белән үтисең. Ләкин тактага, укытучыга карарга кирәк булганда, муеннарың каерылып бетә инде.

*Уңай ягы:* фикерләргә өйрәнәсең, үзең чыгарган кагыйдә хәтердә яхшырак саклана, аңлап каласың. Теманы синә үз сүзләре белән классташың аңлатканда, уку ничектер җиңелрәк бирелә.

*Уңайсыз ягы:* Дәрестә йоклап булмый, туктаусыз эшләргә кирәк. *(көлә)*

**Зәйнәп Нассер – гимназия Укучылар үзидарәсенең Мәгариф министры:** Сингапурча укуның төп үзенчәлеге – монда партадашың белән сөйләшергә ярый гына түгел, хәтта кирәк тә. Укытучының эше – проблема тудыру, ул сине сорау алдында калдыра, җавабын син партнёрың белән бергәләп эзләргә тиеш. Әйтик, дәрестә укытучы тактага сүзләр яза яки рәсемнәр күрсәтә. Укучыларга уйларга тәкъдим ителә. Ничек уйлыйсыз, ди укытучы, монда берәр закончалык күрмисезме? Һәм өстәлләрдә фикер алышу, вариантлар тәкъдим итү башлана. Класс уртаклыкларны ачыклый. Шуннан без бүген нинди тема үтәсен үзебез үк эзләп табабыз. Ачыш ясагач, рәхәт булып китә, процесска кереп киткәнеңне сизми дә каласың.

Мондый дәресләрнең тагын бер үзенчәлеге – син кагыйдәне укытучыга түгел, классташыңа сөйлисең. Укытучыга кагыйдә сөйләгәндә иң мөһиме – ялгышмыйча, китапча әйтеп бирү һәм тиешле «биш»леңне алу. Классташыңа сөйләгәндә исә башка нәрсәләргә өстенлек бирелә: кагыйдә аңа аңлашылырга тиеш, димәк, аны үз сүзләрең белән сөйләргә кирәк. Башка кешегә аңлатканда, син үзең дә материалны яхшырак аңлый барасың. Ә инде классташың төпченеп сораулар да бирә башласа, бөтенләй белгечкә әйләнеп китүең дә бар. Безнең дәресләрдә, мәсәлән, өй эшләрен укытучы түгел, классташың тикшерә һәм сиңа үз билгесен куя.

*Уңай ягы:* син дәрестә җавап бирүдән курыкмыйсың.

*Уңайсыз ягы:* бертуктаусыз уйларга туры килә, дәрестә үзең өчен бер минут та калмый. *(көлә)*

**Камилә Ханеева – гимназия Укучылар үзидарәсенең Мәдәният һәм пресса министры.**

Әлбәттә, һәр укытучы, дәрес темасын аңлатканнан соң, бер үк сорау бирә: «Сорауларыгыз калдымы? Нәрсә аңлашылмады?» Ләкин без аны җавап таләп итми торган – риторик сорау итеп кабул итәргә өйрәнгән. Бик аңлап җиткермәсәк тә, өйдә укырмын, аңлармын әле дип, дәшми калабыз. Сингапурча укыганда исә дәшми калу мөмкин түгел: укытучы безгә сораулыклар тарата. Ул анкета формасында: «Мин белдем: …», «Минем мондый сорауларым калды: …», «Мин бу дәрескә кадәр болай уйлый идем: ... ә хәзер: ...». Башта син фразаларны язып чыгасың, партнерың белән киңәшләшеп аласың, аннары укытучыга әйтәсең. Өйгә кайткач, үзегез чыгарган кагыйдәнең китапча вариантын карап, күнегүләр генә эшлисе кала.

*Уңай ягы:* укытучы синең материалны үзләштерү-үзләштермәвеңне белеп тора, кичекмәстән ярдәмгә килә.

*Уңайсыз ягы:* син укытучың өчен «серле йомгак» булудан туктыйсың.



**Гомумән, Сингапур структураларын дәресләрдә уңышлы кулланганда:**

- дәрес бик тиз үтә, сәгатькә карамыйсың да диярлек;
- классташы һәр укучы белән аралашасың, бу классны берләштерә;
- дәрес уен итеп кабул ителә;
- лидерлык сыйфатларыңны үстерә;
- иҗадилык тәрбияли;
- үз-үзеңне объектив бәяләргә өйрәнәсең.

***Ханеева Камилә,***
***9 нчы б сыйныфы укучысы***

# УРА, КАНИКУЛ! ИСӘНМЕ, ВК!




**Ого! Ике сообщение килгән! Фотоларга да фикер калдырганнар! Шуларны гына керерп карыйм да өй эшләренә утырам. 2 генә минут, шуннан артыгы түгел! Хәзер... хәзер...**

Вконтакте - иң популяр социаль челтәр. Аны белмәгән кеше юк. ВКны руслар, татарлар, марилар, башкортлар, һ.б. гына түгел, чит илләр дә белә. ВКда утыручы кешеләрнең саны көннәр белән түгел, ә секунд саен арта. ВК музыка, видео-фильмнар, уеннар, яңалыклар белән тулган. Ни өчен соң кешеләр анда утырырга ярата икән? Шул кешеләр арасында син дә бар, мин дә бар, безнең гимназия укытучылары да бар, хәтта президентлар да бар. Шулай ук мин дә ВКда утырырга яратам. Нәрсә тапканмындыр инде шунда. Сез үзүзегезгә сорау бирмисезме? Ә мин бирәм. “Ни өчен утырам? Нәрсә калган соң анда?” Чынлап та, нәрсә?

Әйдәгез әле, ВКның уңай һәм тискәре якларын карап китик.

**Уңай яклары:**

- ерактагы дустың, туганың белән аралаша аласың;
- ОГЭ-ЕГЭга әзер материаллар таба аласың;
- хоббиең белән кызыксына аласың;
- яңа һәм элеккеге дусларыңны таба аласың;
- яңалыклар беләсең;
- музыка дөньясы белән тоташасың.

**Тискәре яклары:**

- вакытыңны бетереп утырасың;
- акча әрәм итәсең;
- күзеңне бетерәсең;
- дусларың белән виртуаль аралашасың.
- сәламәтлеккә зыянлы.

Мин ВКда көннәр буе утыруның зыяны турында яшьтәшләремә сөйли башлагач, барысы да: “Үзең дә утырасың!” – дип, күземне дә ачырмадылар. Ни өчен нәкъ ВКны сайлауларын сорагач, күбесе мондый фикер әйтте: “Бөтенесе утыра бит!”

7 нче а сыйныфы укучыларына түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать иттем.

1. ВКда ничәнче елдан бирле утырасың?
2. Ни өчен утырасың?
3. Зыянлымы, файдалымы?

**Айгөл:** 2010 елда сәхифәмне төзедем. Шуннан китте инде...

Казанда укучы апамның хәлен беләм. Дуслар белән языешам, аралашам, хәлләрен сорыйм. Бәйрәмнәргә әзерләнү өчен видеолар карыйм.

Файдалы ягы да бар, ләкин күп вакытны ала. Бер кереп китсәм, чыга алмыйм.

**Настя:** 2010 елның 24 нче июненнән бирле.

Дусларым белән аралашам, фотолар карарга яратам.

Файдалы.

**Илгиз:** 2010 елдан. Яңа дуслар табам, аралашам.

Яңалыклар карыйм. Скайп аша дуслар, туганнар белән сөйләшәм.

Файдалы.

**Илнар:** 10 яшьтән бирле...

Бөтенесе утыра бит. Мин генә калыйм мени.

Зыянлы, бик еш спам килә.

**Раил:** 2009 елның 18 ноябреннән...

Эш юк. *(көлә)* Чынлап та...

Зыянлы да, файдасы да бар.

**Миләүшә:** 4 нче класстан бирле утырам.

Кызык бит. Дөнья белән бергә барасым килә. Группалардан төрле рецептлар эзлим, кулдан ясый торган уенчыклар, бәйләм үрнәкләре табам.

Файдалы.

**P.S.** Сораштыру нәтиҗәләре ВКонтактеның зыянлы һәм файдалы якларын күрсәтә. Һәм бу ялган түгел. Дусларым файдалы дип уйласалар да, фикеремне үзгәртмим. ВКда күп утырмагыз. Соңыннан үкенерлек булмасын.

Киңәшләр:

- ВКда утыруыңны кимет;
- спорт яки хоббиең белән шөгыльлән;
- китап укырга онытма;
- урамга чык, саф һава сула.

***Кашапова Илүзә,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## Әйдәгез, китап укыйк.

XXI гасыр - компьютерлар, ноутбуклар, телефоннар, планшетлар заманы. Ә китап уку заманы томанда кала түгелме?! Әйе, барыбыз да хәзер шул экраннарга төбәлгәнбез, бар дөньябызны онытып, шуларга чумганбыз. Ә бит бу дөньяда күпме кызыклы һәм мавыктыргыч әйберләр бар! Мәсәлән, спорт! Спорт стресстан арынырга һәм иң мөһиме - сәламәт булырга булыша. Тагын бер бик тә мөһим әйберләрнең берсе - ул әлбәттә, уку! Китап, гәҗит, журналлар, мәсәлән, “Ялкын”! Уку ни өчен кирәк, дисеңме? Әлбәттә, дәрес язу, күпне белү һәм итәгатьле итеп сөйләшү өчен кирәк. Дустым, мин иң мөһим булган әйберләрне генә әйттем, аларның бит очы-кырые юк! Музыка коралларында уйнарга өйрәнергә, күп төрле бәйгеләрдә катнашырга була. Кыскасы, камиллекнең чиге юк! Сез буш вакытыгызны ничек уздырасыз? Сөйләшүгә чакырабыз! Хатларыгызны электрон почтага җибәрегез: tilsim.gimnazia@yandex.ru.

Алдашмыйм мин, чын әйтәм, быелга кадәр татарча китап укыганым бик сирәк иде. Күбрәк урысча укыйм шул, чөнки татарча китапларда мин аңламаган сүзләр күбрәк, ә сүзләрен аңламагач, эчтәлеген дә аңларга авыр. Китапханәгә татар теле укытучыбыз мәҗбүр иткәнгә генә язылган идем, татар китабының тәмен белә башладым бугай. Соңгы вакытта мин Алмаз Гыймадиевнның «Телефонлы кәҗә», Галимҗан Гыйльмановның «Илекәй батыр», Фәүзия Бәйрәмованың «Алыплар илендә», “Бәхет ачкычы” китапларын бик яратып укыдым. Гимназия китапханәсендә татарча китаплар бихисап! Хәтта татарча энциклопедия дә бар икән! Фәрит Яхин хикәяләвендәге «Пәйгамбәрләр тарихы» күңелемдә калды. Бу китапта Идрис, Нух, Һуд һәм башка пәйгамбәрләр турында язылган. Күңелем гөнаһлардан, ямьсез гамәлләрдән чистарган кебек тоелды, сафланып киткәндәй булдым. Минем кешегә яхшылык кына эшлисем, Пәйгамбәрләр сыман түземле, сабыр, саф күңелле буласым килә. Минем фикеремчә, китапның кешегә тәэсир көче зур. Китапны яратыгыз!

***Сабитова Айгөл,***
***7 нче а сыйныфы укучысы***

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ: КӨН ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Гимназиядә “Тормыш дәресләре” кысаларында тәрбияви эчтәлекле чаралар узды. Аларда районыбызның күренекле шәхесләре чыгыш ясады. 9-11 нче сыйныф укучылары район күләмендә уздырылган геройларны искә алу митингында катнашты.”Татар әдәбияты көннәре”ндә уздырылган чаралар да укучыларда матур тәэсир калдырды.

Бөтендөнья «Код сәгате» акциясендә гимназия укучылары һәм укытучылары актив катнашты. Фойеда урнаштырылган интерактив өстәлдә логик мәсьәләләр чишәргә мөмкин тудырылды. IT-белгечләр киләчәктә тормышның барлык сфераларына да үтеп керәчәк. Дәресләрдә, мастер-классларда укучылар үзләрен программистлар итеп хис иттеләр. Атналык нәтиҗәле үтте, актив укучылар сертификатларга ия булды.

Татар теленнән халыкара олимпиаданың читтән торып эшли торган турында гимназиянең 9-11 нче сыйныф укучылары бик теләп катнаштылар. Алар арасында биремнәрне 91% эшләүчеләр дә шактый. Алдагы этапларда уңышлар телибез!

“Китапларга икенче тормыш!” девизы астында “Китапханәгә ярдәм” акциясендә катнашып, гимназия укытучылары китапханә фондына 19 мең сумлык дәреслек сатып алдылар. Әлеге акциядә укучылар да катнашты. Иң актив класслар - 11а (Шәймөхәмәтова Ч.Р.) һәм 11в (Миңнегалиева Л.Р), 11б (җитәкчесе Шәнгәрәева З.Н.).

1-10 декабрьдә макулатура җыю ункөнлеге барды. Иң актив сыйныфлар: 9а һәм 8а! Афәрин! 400 шәр кг җыйдылар! Иң күп җыючы укучылар: Абдуллин Азат, Латыйпов Ленар.

## “Яңа ел - 2015” фоторепортаж



**ТЫЛСЫМ+**

Декабрь, 2014 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Ханеева Камилә
**Корректорлар:** Муллагалиева Алсу, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Сәфәргалина Инзилә, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галеев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Маннанов Илдар
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym